**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в отдельные законодательные акты Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
15 апреля 2026 года

## Статья 1

Внести в статью 24 Закона Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 7 (II часть); 2005, № 2, № 4 (I часть), № 6 (II часть), № 11; 2006, № 4, № 7 (I часть); 2007, № 7 (I часть), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (II часть); 2011, № 3, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2013, № 3, № 7, № 12 (I часть); 2014, № 5, № 11 (VI часть); 2015, № 7 (I часть), № 11 (I часть); 2016, № 3, № 5, № 6 (I часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 27 (часть I), № 55 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 22 (часть I), № 54 (часть I), № 78 (часть I), № 92 (часть I); 2019, № 19 (часть I); 2020, № 1 (часть I), № 4 (часть I), № 37 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 36 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 17 (часть I), № 24 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 27 (часть I), № 73 (часть I), № 81 (часть I), № 92 (часть I), № 96 (часть I); 2024, № 18 (часть I), № 47 (часть I), № 56 (часть I), № 76 (часть I), № 79 (часть I), № 93 (часть I); 2025, № 18 (часть I), № 49 (часть I); 2026, № 25 (часть I) изменение, дополнив ее частью $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$. В соответствии с принципом единства системы публичной власти глава муниципального района и глава городского округа одновременно замещают государственную должность Республики Татарстан и муниципальную должность.».

## Статья 2

Внести в часть 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 3 (I часть); 2007, № 7 (I часть); 2008,

№ 7 (II часть), № 12 (I часть); 2009, № 12 (II часть); 2010, № 1 – 2, № 4 (I часть); 2011, № 5; 2012, № 7 (I часть); 2013, № 2 (I часть), № 3, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7, № 12 (II часть); 2015, № 11 (I часть); 2016, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I); 2018, № 1 (часть I); 2020, № 37 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 57 (часть I); 2022, № 83 (часть I); 2023, № 27 (часть I), № 35 (часть I), № 73 (часть I), № 92 (часть I); 2024, № 47 (часть I), № 56 (часть I), № 93 (часть I); 2026, № 25 (часть I) изменение, дополнив ее словами «, глав муниципальных районов и глав городских округов».

**Статья 3**

Внести в Закон Республики Татарстан от 12 февраля 2009 года № 15-ЗРТ «О гарантиях осуществления полномочий депутата представительного органа муниципального образования, члена выборного органа местного самоуправления, выборного должностного лица местного самоуправления в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II часть); 2014, № 6 (II часть), № 12 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2018, № 1 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 26 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 77 (часть I); 2022, № 3 (часть I); 2023, № 92 (часть I); 2024, № 47 (часть I), № 79 (часть I) следующие изменения:

1) в наименовании слова «депутата представительного органа муниципального образования, члена выборного органа местного самоуправления, выборного должностного лица местного самоуправления» заменить словами «лиц, замещающих муниципальные должности»;

2) в статье 1:

а) часть 1 изложить в следующей редакции:

«1. Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 20 марта 2025 года № 33-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в единой системе публичной власти» предусматривает гарантии осуществления полномочий лиц, замещающих муниципальные должности в Республике Татарстан.»;

б) абзац второй части 2 признать утратившим силу;

в) в части 4 слова «Федеральном законе от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации» заменить словами «Федеральном законе от 20 марта 2025 года № 33-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в единой системе публичной власти»;

3) дополнить статьей $2^1$ следующего содержания:

«Статья $2^1$. **Дополнительные гарантии, предоставляемые лицу, одновременно замещающему государственную должность Республики Татарстан и муниципальную должность**

1. Лицу, одновременно замещающему в соответствии с принципом единства системы публичной власти государственную должность Республики Татарстан и муниципальную должность, дополнительно к гарантиям, предусмотренным статьей 2 настоящего Закона, предоставляются следующие гарантии:

1) один раз в год единовременная денежная выплата при предоставлении ежегодного оплачиваемого отпуска в размере двух месячных денежных вознаграждений, которая по желанию лица, указанного в абзаце первом настоящей части, может быть произведена в другое время, в порядке и на условиях, установленных Кабинетом Министров Республики Татарстан;

2) единовременная денежная выплата на санаторно-курортное лечение, проезд к месту отдыха и обратно в размере одного месячного денежного вознаграждения в порядке и на условиях, установленных Кабинетом Министров Республики Татарстан;

3) единовременное денежное вознаграждение в связи с выходом на пенсию с должности, указанной в абзаце первом настоящей части, при наличии права на ежемесячную доплату к страховой пенсии по старости (инвалидности) (далее – доплата к пенсии) в соответствии с настоящим Законом в размере десятикратного месячного денежного вознаграждения, установленного по замещаемой должности, в порядке и на условиях, установленных Кабинетом Министров Республики Татарстан;

4) единовременная субсидия на приобретение жилья один раз за весь период замещения должности, указанной в абзаце первом настоящей части, в порядке и на условиях, установленных федеральным законодательством, настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

2. В случае смерти лица, указанного в части 1 настоящей статьи, членам семьи, другим родственникам или иным лицам, осуществляющим его похороны, возмещаются расходы на погребение и ритуальные услуги в порядке и на условиях, установленных Кабинетом Министров Республики Татарстан.

3. На лиц, указанных в части 1 настоящей статьи, не распространяются положения, предусмотренные пунктом 4 части 2 статьи 3 настоящего Закона.

4. Финансирование расходов, предусмотренных настоящей статьей, осуществляется за счет средств бюджета Республики Татарстан.»;

4) в абзаце первом части 2 статьи 3 слова «нормативными актами» заменить словами «настоящим Законом и иными нормативными правовыми актами»;

5) в статье 6:

а) в части 1:

в абзаце первом слова «ежемесячной доплаты к страховой пенсии по старости (инвалидности) (далее – доплата к пенсии)» заменить словами «доплаты к пенсии», слова «при условии» заменить словами «, при одновременном соответствии следующим условиям»;

в пункте 1 слово «замещения» заменить словом «замещение»;

в абзаце первом пункта 2 слово «освобождения» заменить словом «освобождение»;

в пункте 3 слово «замещения» заменить словом «замещение»;

в пункте 4 слово «достижения» заменить словом «достижение»;

б) в части 4 слова «депутатов, выборных должностных лиц местного самоуправления, осуществляющих свои полномочия» заменить словами «лиц, замещающих муниципальные должности»;

в) в части $8^1$ слова «депутатов, выборных должностных лиц местного самоуправления, осуществляющих свои полномочия» заменить словами «лиц, замещающих муниципальные должности».

**Статья 4**

1. Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

2. Действие положений части 2 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 4 марта 2006 года № 16-ЗРТ «О государственных должностях Республики Татарстан» (в редакции настоящего Закона) распространяется на правоотношения, возникшие с 19 июня 2025 года.

3. Действие положений статьи $2^1$ Закона Республики Татарстан от 12 февраля 2009 года № 15-ЗРТ «О гарантиях осуществления полномочий лиц, замещающих муниципальные должности в Республике Татарстан» распространяется на правоотношения, возникшие с 1 января 2026 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
25 апреля 2026 года
№ 28-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 15 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 76 (I өлеш), № 79 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2026, № 25 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$1^1$. Гавами хакимият системасының бердәмлеге принцибы нигезендә муниципаль район башлыгы һәм шәһәр округы башлыгы Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны бер үк вакытта били.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2026, № 25 (I өлеш), «җәмәгать судьяларына» сүзләреннән соң «, муниципаль районнар башлыкларына һәм шәһәр округлары башлыкларына» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (часть I); 2019, № 2 (часть I); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш); 2023, № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты» сүзләрен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Закон «Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләрен күз алдында тота.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

в) 4 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законндагы» сүзләрен «Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закондагы» сүзләренә алмаштырырга;

3) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ статья өстәргә:

«2[1] статья. **Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны бер үк вакытта биләүче затка бирелә торган өстәмә гарантияләр**

1. Гавами хакимият системасының бердәмлеге принцибы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын һәм муниципаль вазыйфаны бер үк вакытта биләүче затка әлеге Законның 2 статьясында каралган гарантияләргә өстәмә рәвештә түбәндәге гарантияләр бирелә:

1) еллык түләүле отпуск бирелгәндә елга бер мәртәбә ике айлык акчалата бүләкләү күләмендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү, ул әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән зат теләге буенча башка вакытта бирелергә дә мөмкин;

2) шифаханә-курорт дәвалануы, ял итү урынына бару һәм кире кайту өчен бер айлык акчалата бүләкләү күләмендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү;

3) әлеге Закон нигезендә картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә ай саен өстәмә (алга таба – пенсиягә өстәмә) алу хокукы булган очракта, әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, биләгән вазыйфа буенча билгеләнгән ун айлык акчалата бүләкләү күләмендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү;

4) торак сатып алу өчен әлеге өлешнең беренче абзацында күрсәтелгән вазыйфаны биләүнең бөтен чорына бер мәртәбә федераль законнарда, әлеге Законда һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда бер тапкыр бирелә торган субсидия.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән зат вафат булган очракта, гаилә әгъзаларына, башка туганнарына яисә аны җирләүче башка затларга җирләү һәм ритуаль хезмәт күрсәтү чыгымнары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда кире кайтарыла.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затларга әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 4 пунктында каралган нигезләмәләр кагылмый.

4. Әлеге статьяда каралган чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

4) 3 статьяның 2 өлешендәге беренче абзацында «Татарстан Республикасының норматив актлары белән» сүзләрен «әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән» сүзләренә алмаштырырга;

5) 6 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «түбәндәге шартларда» сүзләрен «, түбәндәге шартларга бер үк вакытта туры килгәндә,» сүзләренә алмаштырырга, «нигезендә билгеләнгән картлык (инвалидлык) буенча иминият пенсиясенә айлык өстәмә (алга таба –

пенсиягә өстәмә)» сүзләрен «белән билгеләнгән пенсиягә өстәмә» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «биләсә» сүзен «биләгәндә» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктның беренче абзацында «азат ителсә» сүзләрен «азат ителгәндә» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «биләсә» сүзен «биләгәндә» сүзенә алмаштырырга;

4 пунктта «җитсә» сүзен «җиткәндә» сүзенә алмаштырырга, «билгеләнсә» сүзен «билгеләнгәндә» сүзенә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары» сүзләрен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның» сүзләренә алмаштырырга;

в) $8^1$ өлештә «җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының» сүзләрен «муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның» сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2025 елның 19 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. «Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 25 апрель
№ 28-ТРЗ